## КАРАР

**2022 елның 30 ноябре** **№ 29**

**Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлегенең Пычак авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәсе турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 25 ноябрендә 19.00 сәгатьтә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе тәзелде:

«Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлегенең Пычак авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидларыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлардан (курсантлар), 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, үзара салымны 700 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Пычак авылының Мәхмүт Яхин урамында тышкы видеокүзәтү камералары сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр;
- Пычак авылының Мәхмүт Яхин урамында юлга асфальт җәю (проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, экспертиза);
- Пычак авылының Мәхмүт Яхин урамында, юлларга вак таш җәеп, чокырларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, җәю, (проект-смета документларын эшләү, килешү буенча эш өчен түләү);
- Пычак авылының Мәхмүт Яхин урамына юл билгеләре сатып алу һәм урнаштыру (проект-смета документларын эшләү, килешү буенча эш өчен түләү);
- янгын сүндерү җиһазлары сатып алу һәм урнаштыру;
- Пычак авылына коелар, капкачлар һәм янгын сүндерү гидрантлары сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Пычак авылы территориясен төзекләндерү (проект-смета документларын эшләү, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Пычак авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм территорияне җәй көне чабу; ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)
- клуб өчен спорт җиһазлары сатып алу;
- чишмәне ремонтлау һәм карап тоту, ремонт өчен төзелеш материаллары сатып алу (проект-смета документларын әзерләү һәм килешү буенча түләү);

- зират өчен җиһазлар сатып алу; зират территориясен төзекләндерү (вак таш сатып алу, ташу, җәю, зират юлларына һәм зиратның транспорт кую урынына вак таш җәю) (проект-смета документларын әзерләү һәм эш өчен килешү буенча түләү);

- Псяк авылы балалар мәйданчыгын төзекләндерү (балалар мәйданчыгы өчен төзелеш материаллары һәм җиһазлар сатып алу )

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены карары нигезендә: Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә **119** кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны **64**.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 64 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан **0** кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлеге Пычак авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлегенең Пычак авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидларыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлардан (курсантлар), 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, үзара салымны 700 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

«РИЗА» «КАРШЫ»

- кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Пычак авыл җирлеге башлыгы Г.Ш. Нәфыйков

ОГРН 1021607752979
ИНН 1623001928